ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

26.03.2026 Олы Кайбыч ав. № 170

**Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы торак пунктларында төзеклэндерү, чисталык һәм тәртип урнаштыру буенча икеайлык үткәрү турында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2026 елның 19 мартындагы 462-р номерлы күрсәтмәсе нигезендә һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы торак пунктларын санитар чистартуны тәэмин итү, аларны халыкның экологик һәм санитар-эпидемиологик иминлегенә җавап бирә торган хәлгә китерү максатларында, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. Районда 2026 елның 1 апреленнән 31 маена кадәр Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының торак пунктлары территорияләрен чистарту буенча санитар-экологик икеайлык игълан итәргә (алга таба - икеайлык).
2. Икеайлык үткәрү эшләрен координацияләү өчен оператив штаб булдырырга һәм аның составын расларга (1 нче кушымта).
3. . Район территориясен санитар чистарту планын расларга (2 нче кушымта).
4. Авыл җирлекләре башлыкларына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

икеайлык үткәрү турындагы мәгълүматны оешма һәм халык җитәкчеләренә җиткерергә;

ведомство буйсынуындагы территорияләрне санитар чистарту планнарын эшләргә;

икеайлык үткәрү эшләрен координацияләү өчен оператив штаблар булдырырга;

җирле үзидарә органнарының административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затларының җирлекләр һәм шәһәр округлары территорияләрен төзекләндерү буенча муниципаль кагыйдәләрнең, калдыклар белән эш итүнең муниципаль кагыйдәләренең үтәлешен тикшереп торуны көчәйтү өлешендә эшчәнлеген активлаштырырга;

су объектларының, пляжларның, скверларның, балалар мәйданчыкларының, азык-төлек һәм кием базарларының, халыкның күпләп ял итү урыннарының, ял итү базаларын, бакчачылык җәмгыятьләренең һәм гараж кооперативларының, хосусый торак сектор территорияләрен, ташландык биналар, иске корылмалар һәм корылмаларны санитар чистарту чараларын уздырырга, алга таба автомобиль юлларының юл буе полосаларын, контейнер мәйданчыкларын төзү һәм ремонтлау, каты көнкүреш калдыклары өчен контейнерлар әзерләү һәм ремонтлау буенча чаралар үткәрергә;

каты көнкүреш һәм биологик калдыкларның (үләт базларының) полигоннарын тиешенчә карап тотуны һәм эксплуатацияләүне тәэмин итү һәм алар янындагы урыннарны санитар чистарту чараларын күрергә;

терлекчелек комплекслары калдыкларын рөхсәтсез урнаштыру урыннарын бетерү чараларын күрергә;

ведомство буйсынуындагы территорияләрне санитар-экологик чистарту эшенә ирекле нигездә иҗтимагый яшьләр (волонтерлык) оешмаларын җәлеп итәргә;

ведомство буйсынуындагы территориядә калдыкларны рөхсәтсез урнаштыруның барлыкка килгән урыннарына «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасы, «Мәктәп экопатруле»мобиль кушымтасы ярдәмендә мониторинг үткәрергә;

Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлегенә икеайлыкны уздыру барышы турында әлеге күрсәтмәнең 3 нче кушымтасы нигезендә атна саен сишәмбе көннәрендә, әлеге карарның 4 нче кушымтасындагы форма нигезендә мәгълүмат бирергә.

5. «Хикмәтуллин Рөстәм Тәлгать улы» ШЭ торган каты көнкүреш калдыкларын кабул итү һәм күмү полигоннарына чүп-чарны чыгару буенча коммуналь техниканың нәтиҗәле эшләвен тәкъдим итәргә.

6. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы административ комиссиясенә җирлекләр территорияләрен төзекләндерүнең муниципаль кагыйдәләре, калдыклар белән эш итүнең муниципаль кагыйдәләре үтәлешенә контрольне көчәйтү өлешендә эшне активлаштырырга.

7. «Кайбыч таннары» («Кайбицкие зори») газетасының баш мөхәрриренә газетада икеайлык барышын яктыртуны тәкъдим итәргә.

8. Халык, барлык милек рәвешләрендәге оешмалар коллективлары катнашында район үзәген, торак пунктларын, күпләп ял итү зоналарын төзекләндерү һәм санитар чистарту буенча чаралар үткәрүне даими практикага кертергә.

9. Башкарма комитетның инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы Ю.В. Гайнуллинага икеайлыкны үткәрү эшләренең барышы турында Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгына әлеге карарга 3 нче кушымтадагы форма буенча атна саен чәршәмбе көнне 12.00 сәгатькә кадәр, әлеге карарга 4 нче кушымтадагы форма буенча мәгълүмат бирергә.

10. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы торак пунктларында төзекләндерү, чисталык һәм тәртип урнаштыру икеайлыгын үткәрү турында» 2025 елның 13 мартындагы 104 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

11. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга һәм http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталы» нда бастырып чыгарырга.

12. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык буенча урынбасары Е.Г.Давыдовага йөкләргә.

Җитәкче А.Н. Макаров

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Башкарма комитетының
2026 елның 26 мартындагы
170 номерлы карарына
1 нче кушымта

**Икеайлык үткәрү эшләрен координацияләү өчен оператив штаб составы**

| | |
|---|---|
| Давыдова Е.Г. | Башкарма комитет Җитәкчесенең төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык буенча урынбасары |
| Камалетдинов Р.М. | Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы (килешү буенча) |
| Решеткина Н.И. | Татарстан Республикасында Зеленодольск, Югары Ослан, Кама Тамагы районнарында «Гигиена һәм эпидемиология үзәге» федераль бюджет сәламәтлек саклау учреждениесе филиалының Кайбыч бүлеге мөдире (килешү буенча) |
| Шәфиев А.Р. | Россия Эчке эшләр министрлыгының Кайбыч районы буенча бүлекчәсе башлыгы (килешү буенча) |
| Сабирҗанов Р.Р. | Кайбыч районы дәүләт ветеринария бүлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Сөнгатуллина Л.М. | «Кайбыч таңнары» газетасының баш мөхәррире (килешү буенча) |
| Хәмидуллин И.И. | «Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУ башлыгы |
| Ибраһимов Д.Р. | Федераль янгынга каршы хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча 115 янгын частенең «8 отряды» башлыгы (килешү буенча) |
| Гыйльметдинов Ф.А. | «Кайбыч махсус орлыкчылык хуҗалыгы» ДБУ директоры (килешү буенча) |

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Башкарма комитетының
2026 елның 26 мартындагы
170 номерлы карарына
2 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында санитар чистарту һәм санитар-экологик хәлне яхшырту буенча чаралар планы**

| Тб № | Чараның атамасы | Үтәү вакыты | Башкаручылар |
|---|---|---|---|
| 1 | Район предприятиеләренә һәм оешмаларына 2023 елның 01 апреленнән 31 маена кадәр район торак пунктлары территорияләрен санитар чистарту икеайлыгы уздыру турында хәбәр итү. | 01.04.2026 кадәр | Авыл җирлекләренең Башкарма комитетлары җитәкчеләре (килешү буенча) |
| 2 | Эшләрне координацияләү өчен оператив штаблар булдыру | 25.03.2026 кадәр | Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты |
| 3 | Район оешмалары һәм предприятиеләре мәйданчыкларын, ишегалларын һәм аларга якын территорияләрне санитар чистарту эшләрен башкару | 01.05.2026 кадәр | Район оешмалары һәм предприятие-ләре (килешү буенча), биналар һәм корылмалар милек-челәре, торак пункт-ларда яшәүчеләр (килешү буенча) |
| 4 | Биналарның һәм торак йортларның фасадларын ремонтлау | 31.05.2026 кадәр | Район оешмалары һәм предприятие-ләре (килешү буенча), биналар һәм корылмалар милек-челәре (килешү буенча) |
| 5 | Балалар мәйданчыкларын төзекләндерү һәм чистарту | 31.05.2026 кадәр | авыл җирлекләре Башкарма комитет-лары (килешү буенча) |
| 6 | Иске агачларны кисү, коймаларны ремонтлау һәм буяу | апрель-май | авыл җирлекләре Башкарма комитет-лары (килешү буенча) |
| 7 | «Кошларга йорт» конкурсы | 2026 елның апреле | Белем бирү учреждениеләре |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 8 | Обелискларны, һәйкәлләрне һәм аларга якын территорияләрне ремонтлау һәм төзекләндерү | 01.05.2026 кадәр | авыл җирлекләре Башкарма комитетлары (килешү буенча) |
| 9 | «Кошлар көне» бәйрәме | 2026 елның 01-04 апреле | Мәгариф учреждениеләре |
| 10 | «ЭКОЛОГ һәм Мин» конкурсы | 2026 елның апреле | «ЭКО» мәктәптән тыш эшләр үзәге |
| 11 | Макулатура җыю акцияләре | 2026 елның апрель-май айлары | Мәгариф учреждениеләре |
| 12 | Клумбалар ясау һәм ремонтлау, чәчәк утырту, агач һәм куаклар утырту | 01.06.2026 кадәр | Район оешмалары һәм предприятие-ләре (килешү буенча), авыл җир-лекләре Башкарма комитетлары |
| 13 | Районның электр линияләре баганаларын , агачлар, куаклар агарту | 01.05.2026 кадәр | Район оешмалары һәм предприятие-ләре (килешү буенча), авыл җир-лекләре Башкарма комитетлары |
| 14 | Рөхсәтсез чүплекләрне ачыклау һәм бетерү | 2026 елның апрель-мае. | авыл җирлекләре Башкарма комитетлары (килешү буенча) |
| 15 | Беркетелгән территорияләр нигезендә юл буе полосаларын һәм юл кырыйларын җыештыру, | 01.05.2026 кадәр | Район оешмалары һәм предприятие-ләре (килешү буенча), авыл җир-лекләре Башкарма комитетлары |
| 16 | Чишмәләрне төзекләндерү һәм карап тоту | 2026 елның май-июнь айлары | авыл җирлекләре Башкарма комитетлары (килешү буенча) |
| 17 | Зиратларны төзекләндерү, чистарту һәм коймаларын төзекләндерү | 2026 елның апрель-май айлары | авыл җирлекләре Башкарма комитет-лары (килешү буенча) |
| 18 | Әйләнә-тирә мохитне саклау буенча дәресләр | 2026 елның апрель-май айлары | Белем бирү учреждениеләре |
| 19 | «Яшел патруль» балалар рәсеме конкурсы | 2026 елның 15 апреленә кадәр | Мәгариф учреждениеләре |
| 20 | Нәтиҗәләр ясау | атна саен | Ав. җир-ре Башкар-ма комитетлары җи-тәкчеләре (килешү буенча), оешмалар һәм предприятиеләр (килешү буенча) |

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Башкарма комитетының
2026 елның 26 мартындагы
170 номерлы карарына
3 нче кушымта

## 2026 елның «_____» ___________ ведомстволар эше турында мәгълүмат

| т/б № | Муниципаль берәмлек исеме | Ачыкланган тәртип бозулар | | ачыкланган калдыкларны санкциясез урнаштыру урыннары | | | Калдыкларны санкцияләнмәгән урнаштыру урыннары бетерелде | | | РФ Административ хокук бозулар турында кодексының ______ маддәсе (Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексы) буенча беркетмәләр төзелде, данә | | | | Административ җаваплылыкка тартылды | | | | Салынган штрафлар, мең сум | Алынган штрафлар, мең сум | Кисәтүләр бирелде |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Барлыгы | Алардан юкка чыгарылды | саны, данә | Мәйдан, кв. метр | күләм, куб. метр | саны, данә | Мәйдан, кв. метр | күләм, куб. метр | Барлыгы | Юридик затларга | вазыйфаи затларга | Гражданнарга | Барлыгы | Юридик затлар | Вазыйфаи затлар | Гражданнар | | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 | 20 | 21 |
| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |

Җитәкче _______________________________________ _______________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме) (имза)

Искәрмә. Мәгълүматны хисап датасына (арта бару тәртибендә), әлеге кушымтага өстәмә нигезендә, фото-раслау теркәп (ачыкланган һәм юк ителгән) җиткерергә.

| т/б № | Хокук бозу урынының адресы | Мәйданы, кв.метр | Күләме, куб.метр | Статус (юк ителгән / Юк ителмәгән) | Фотоматериал (ачыкланган / юк ителгән) |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| 1. | | | | | |
| 2. | | | | | |
| 3. | | | | | |

_______________________________________

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Башкарма комитетының
2026 елның 26 мартындагы
170 номерлы карарына
4 нче кушымта

Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башкарма комитетлары мәгълүматы
2026 елның «___»______________ торышына карата санитар-экологик икеайлык үткәрү эшләре барышы турында

| т/б № | Муниципаль берәмлек исеме | Чыгарылган каты көнкүреш калдыклары күләме, куб метр. | | Махсус автотранспорт, берәмлек катнашты | Халык, кеше катнашты | Агач утыртылды, данә | Куаклар утыртылды, данә |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | барлыгы | Шул исәптән полигоннарга | | | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |

Җитәкче ________________________________________ _____________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме) (имза)

Искәрмә: Хисап датасына булган мәгълүматлар буенча (үсә баручы нәтиҗә белән) мәгълүмат бирергә.

___________________________________